ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

с. Верхний Услон

2024 елга Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
гомуми белем бирү учреждениеләрендә
норматив чыгымнарны раслау турында.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 12 декабрендәге 588 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2024нче елга кушымталарны расларга:
Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар (1 нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет Палатасына әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе　　　　　　　　　　Р.А. Фәйрушин

Әзерләде һәм бастырды
Ф. М. Әхмәтова

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «__» _______ 20____ № ___ карары белән
Расланды

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Гомуми белем бирү оешмасы тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 108826 |